## СУГА ГЫНА КИТКӘН ӘНИЕМ

Роберт Тимербаев көе

(Зәйнәп Фәрхетдинова репертуарыннан)

Бала чакта суга барам диеп,
Ташлап китә иден, әнием.
Күзкәйләрен тәрәзләрдән алмый
Көтә иде сине нәниең.

*Кушымта:*
Кайда икән әнкәй, кайда икән?
Чишмәләрдән китмәс ул ары.
Юк, үлмәгән әнкәй, югалмаган,
Суга гына киткән нибары.

Юл буенда үскән чәчәкләрдән
«Кайда әни?» диеп сорыймын.
Ак чәчәкләр миңа җавап бирә:
«Соңлагандыр бераз, мөгаен...»

*Кушымта.*

Су буенда үскән тал кызлары
Әнкәм җырын әллә көйлиләр.
Алар белә: суга диеп киткәч,
Мәңгелеккә китми әнкәйләр.

*Кушымта.*